**КАРАР №48**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Советы утырышы

20 июнь 2022 ел                                                  Күлле-Киме авылы

**Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 июнендәге 75 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2017 елның 5 декабрендәге 389-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» , 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 56 статьясындагы 2 өлеше (алга таба - җирле үзидарә турында Закон) нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 июнендәге 75 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә" Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы прокуратурасының 2022 елның 16 мартындагы 02-08-02/Прдп133-22-2092010 номерлы протестын карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 июнендәге 75 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктының өченче абзацында, 2-4 бүлекләрендә, 5.1, 6.1-6.4 пунктларында "җирле референдум турында" сүзләрен "гражданнар җыенында"сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы                                  Х.Х.Гәрәев